**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2407**
**22.05.2020**

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәтләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирләрне рекультивацияләүне һәм консервацияләүне үткәрү турында» 2018 елның 10 июлендәге 800 номерлы Карарының 15 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 24 июнендәге 3237 номерлы, 2016 елның 13 декабрендәге 6675 номерлы, 2017 елның 8 февралендәге 588 номерлы, 2017 елның 3 маендагы 2747 номерлы, 2017 елның 28 сентябрендәге 5805 номерлы, 2018 елның 18 июлендәге 4000 номерлы, 2018 елның 27 июлендәге 4226 номерлы, 2018 елның 2 августындагы 4343 номерлы, 2018 елның 22 ноябрендәге 6940 номерлы, 2019 елның 5 мартындагы 1144 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 2663 номерлы, 2019 елның 8 ноябрендәге 5755 номерлы, 2020 елның 7 февралендәге 545 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган муниципаль хезмәтләр исемлегенә, түбәндәге эчтәлектәге 89, 90 пунктларны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

1) «89. Рекультивация проектын капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә проект документлары составында әзерләү очракларыннан һәм федераль законнар белән билгеләнгәнчә, җирләрне рекультивацияләү проекты расланганчы ул дәүләт экспертизасы үтәргә тиешле очраклардан тыш, җирләрне рекультивацияләү проектын килештерү.»;

2) «90. Җирләрне консервацияләү проектын килештерү.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов